СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**26 декабрь, 2024 ел** **№ 485**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 21 ноябрендәге 350 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Биектау муниципаль районы Уставына таянып, муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Биектау муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 21 ноябрендәге 350 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. IV бүлекне түбәндәге эчтәлекле 4.1.9 пунктчасы белән тулыландырырга:

«4.1.9. Стела - үз фундаментында урнашкан һәм хәтта зур ераклыктан да күренгән аерым торучы зур реклама конструкциясе. Реклама стелаларын автозаправкалар, эре сәүдә үзәкләре, комплекслар һәм башка оешмалар куллана. Стела индивидуаль проект буенча башкарыла. Кече габаритлылар - 3-6 метр

үлчәмле конструкцияләр. Уртача һәм эре габаритлылар - аларның күләмнәре 6-30 метр биеклектәге диапазонда».

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: https://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча игълан итәргә.

Совет рәисе,
муниципаль районы Башлыгы Р.Ф. Хисамөтдинов